СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваш авылы,
422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

08.11.2024 с. Набережные Моркваши 53-306

### Югары Ослан муниципаль районы Яр Моркваш авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә үзара салым кертү һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Яр буе Моркваш авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркваш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2024 елның 23 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваш авыл җирлеге Покровка торак пункты территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваш авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- Покровка торак пунктында Фурцевская урамындагы яшәүчеләргә су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. 13.00 сәгатьтә Покровка авылы, Фурцевская урамы адресы (Административ бина) буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Яр буе Моркваш авыл җирлегенең Башкарма комитеты гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов